Требуется регистрация A4ScanDoc. Пробный период истек. A4ScanDoc.com

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Ямаши авылы башкарма комитеты

КАРАРЫ

6 май 2019 ел

№ 4

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Ямаши авылы башкарма
комитеты карарларының
үз көчен югалтуын тану турында

Муниципаль норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү белән бәйле рәвештә, хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча

Ямаши авылы башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаши авылы башкарма комитетының “Вәкаләтләрнең бер өлешен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру турында”гы 2011 елның 16 сентябрендәге 13а номерлы карарының 1,2,3 пунктларын үз көчен югалткан дип танырга;

2. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаши авылы башкарма комитетының 2012 елның 10 сентябрендәге «Ямаши авылы башкарма комитеты вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыру турында килешүгә үзгәрешләр кертү хакында 2011 елның 16 сентябрендәге” 13а номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Ямаши авылы, Совет урамы, 4 нче йорт; Рокашево авылы, Үзәк урам, 1 нче йорт; Красная Горка авылы, Тихая Аллея урамы, 9 нчы йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә, “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында” (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет" челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны үз артымда калдырам.

Ямаши авыл җирлеге
башкарма комитеты җит□кчесе А.А. Андревкина

Отсканировано программой A4ScanDoc, сайт программы A4ScanDoc.com